# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«26» декабрь 2022 ел Яр Чаллы № 4214

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен арттыру һәм «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның ____ декабрендәге ___ номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 17 сентябрендәге 1013 номерлы карары нигезендә һәм социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүне тәртипкә салу максатында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 1 январеннан бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 26 декабрендәге 4208 номерлы карары белән билгеләнгән айлык вазыйфаи окладлары күләмен арттырырга.

2. Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмен исәпләү өчен әлеге карарның 1 пункты нигезендә бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешманың структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаре

вазыйфаи оклады күләмен 1,061 тапкыр индексацияләргә һәм 12 688 сум күләмендә билгеләргә.

3. «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 26 декабрендәге 4208 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 3 пунктчасында «ике проценты» сүзләрен «15 проценты» сүзләренә алыштырырга;

7 пунктның 4 пунктчасында «ике проценты» сүзләрен «15 проценты» сүзләренә алыштырырга.

4. «Тукай муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин